| **Раздел 3. Разделы науки о языке.** | | | | | |
| 3.1 | Орфоэпия. Орфография | 11 | 1 | | https://magarif-vakyt.ru/online Озвученный русско-татарский онлайн-словарь // URL: www.ganiev.org |
| 3.2 | Морфология | 16 | 1 | | Видеоуроки на родном (татарском) языке // URL: https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/ https://magarif-vakyt.ru/online Портал татарского образования // URL: http://belem.ru |
| 3.3 | Синтаксис. Пунктуация | 35 | 3 | | Видеоуроки на родном (татарском) языке // URL: |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/<br>https://magarif-vakyt.ru/online<br>Портал татарского образования // URL: http://belem.ru |
| Итого по разделу | | 62 | 5 | | |
| Общее количество часов | | 68 | 5 | | |

## ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ
### 9 класс

| № п/п | Наименование разделов и тем программы | Количество часов | | | Электронные (цифровые) образовательные ресурсы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Всего | Контрольные работы | Практические работы | |
| **Раздел 1. Общие сведения о языке. Язык и речь.** | | | | | |
| 1.1 | Общая информация о стилях речи, их особенностях. Работа с текстами о языковых группах мира. | 4 | | | https://magarif-vakyt.ru/online Портал татарского образования // URL: http://belem.ru Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| Итого по разделу | | 6 | | | |
| **Раздел 2. Разделы науки о языке.** | | | | | |
| 2.1 | Фонетика (повторение изученного материала в 5-8 классах). | 11 | 1 | | https://magarif-vakyt.ru/online Портал татарского образования // URL: http://belem.ru |
| 2.2 | Лексикология. Морфемика и словообразование | 11 | 1 | | https://magarif-vakyt.ru/online Видеоуроки на родном (татарском) языке // URL: https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/ |
| 2.3 | Морфология (повторение изученного материала в 5-8 классах). | 17 | 1 | | https://magarif-vakyt.ru/online Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet Видеоуроки на родном (татарском) языке // URL: https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/ Портал татарского образования // URL: http://belem.ru |
| 2.4 | Синтаксис. | 7 | | | Видеоуроки на родном (татарском) языке // URL: https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/ https://magarif-vakyt.ru/online |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.5 | Стилистика. | 16 | 2 | | https://magarif-vakyt.ru/online<br>Портал татарского образования // URL: http://belem.ru<br>Татарский язык: большой электронный<br>свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| Итого по разделу | | 62 | 1 | | |
| Общее количество часов | | 68 | 5 | | |

**Контрольно-измерительные материалы для 5-9 классов**
**«Родной (татарский) язык»**
**базовый уровень**

## 5 нче сыйныфның татар төркеме өчен татар теле буенча бәяләү материаллары

### Изложение

### Көз ахыры.

Көз ахыры иде. Билгеле,күңелсез вакыт. Бакчадагы агачлар яфракларын койганнар. Җырчы кошлар да җылы якка киткәннәр. Тик песнәкләр, чыпчыклар гына калганнар. Алар кыштан курыкмыйлар.

Менә өч көн яңгыр яуды, һәм кинәт кенә суытып җибәрде. Юллар ялтырап торган бозга әйләнде. Сакланып басмасаң, егылып китүең дә бик тиз. Мин өйгә китеп барам. Тауга менә башладым.

Шул таудан бер бабай төшеп килә. Аның бер кулында-бәрәңге тутырган зур кәрзин. Икенче кулында-таяк. Бабай бер атлый да туктый. Таякның ярдәме тими шул.

### *Диктант*

### Кит.

Кит суда яши, ләкин ул балык түгел. Балыклар саңаклары белән сулыйлар, ә китның үпкәләре бар. Аның борыны юк. Борын урынына башында ике тишек бар. Кит шулар аша сулый.

Китның тиресе шома һәм тәңкәсез. Тире астында калын май катламы бар. Ул китның тәнен җылыта. Китның сулавы ерактан күренә. Бу вакытта су өстендә фонтан атылган кебек була.*(“Туган тел” китабыннан)*

### Сочинение “Минем яраткан китабым”

### Диктант

### Дүрткүз.

Абый миңа нәни генә эт баласы бүләк итте. Ул шундый матур. Үзе кара, ялтыравыклы **йонлы,** ак **муенлы**. Алгы тәпиләре аның ак перчатка кигән кебек ап-аклар. Ә күзләре сап-сары. Ике кашы өстендә бармак башы кадәр соры йон таплары бар. Алар нәкъ күз урыны кебек торалар. Шуңа да без эт баласын Дүрткүз дип атадык.

*(А. Алиштан)*

***Бирем.****Билгеләнгән сүзләрнең авазларын билгеләргә*
***Җавап.*** *йонлы - [й,о,н,л,о], муенлы - [м,у,й,ы,н,л,ы]*

### Контроль диктант

### Туган ил кайдан башлана?

Кыш белән язның, җәй белән көзнең үз матурлыгы бар. **Бу матурлык бер-берсен кабатламый.** Елның фасыллары һәммәсе дә матур, гүзәл.

Туган илебез дә карап туймаслык матур һәм бай! Менә шул туган туфрак, туган ил кайдан башлана соң?

Ул син яши торган шәһәрдән, син яши торган авылдан, син укый торган мәктәптән башлана. Туган ягыңны онытма, кечкенә дустым!

**Бирем.** Бирелгән җөмләләрдә баш кисәкләрне билгеләргә.
**Җавап.** Матурлык – ия, кабатламый – хәбәр.

## 6 нчы сыйныфның татар төркеме өчен татар теле буенча бәяләү материаллары

### Изложение

### Костяга мең торна.

Көньяк Сахалин шәһәрендәә яшәүче өч яшьлек Костя Скоропышный кайнап торган суга пешә. Тән тиресенең сиксән процентатан артыгы зарарлана, малайның тормышы кыл өстендә кала. Шул чакта Япониянең Хоккайдо утравы табиблары ярдәмгә килә.

Саппоро шәһәрендә Костяны һәм аның әтисен вертолет көтеп тора. Ул нәни пациентны шифаханәгә илтә.

Япония табиблары Костяга башка тире күчереп утырталар. Хәзер малайның тән температурасы һәм кан басымы нормальләшкән. Ул әтисен таный. Улы янына малайның әнисе дә килә.

Костяның хәле Кояш чыгышы илендә яшәүчеләрнең күбесен борчый. Алар, шифаханәгә шалтыратып, малайның сәламәтлеген сорашып торалар. Хоккайдо утравының бер банкында Костяны дәвалау өчен махсус исәп ачылган. Ә Саппоро шәһәре укучылары һәм балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр Костяга мең кәгазь торна ясап җибәргәннәр. Алар Япониядә озын гомерлелек билгесе булып саналалар икән. Япония малайлары һәм кызлары Костя терелер дип ышаналар. Без дә шуңа өметләнәбез. *(“Сабантуй” газетасыннан)*

**Диктант**

**Имән.**

Безнең авыл уртасында пәһлеван бер имән үсә. Җил-давылга бирешми. Җәй коры килсә, әллә ни исе китми. Дымны тирәннән ала ул. Ул имән ничә яшьтә икән? Мин моны әтидән сорадым. Ул әйтә алмады. Әтием дә әтисеннән сораган. **Бабам да әйтә алмаган. Димәк, ул әтиемнең әтисеннән дә картрак.** Ә бәлки, ул тагын да картрактыр.

Имән утыз яшеннән чәчәк ата. Йөз кырык яшьләрдә ул үсми башлый, юаная бара. (Г.Хәсәновтан)

**Бирем**. Бирелгән җөмләләрдән исемнәрне табып, килешләрен билгеләгез.

**Җавап.**бабам-Б.к.,әтиемнең-И.к.,әтисеннән-Ч.к.

**Сочинение “Туган ягым табигате”**

**Диктант**

**Батырлык һәм тыйнаклык.**

Казан Суворов училищесында булды бу хәл. Бөек Ватан сугышының егерме еллыгын бәйрәм итү тантанасы иде. Залга кара костюмлы хатын килеп керде. Бу училищеның шәфкать туташы Фаина Чанышева иде. Беренче рәттәгеләр сикереп торып урын бирделәр. Өч-дүрт кыз шундук чәчәкләр алып килделәр. Укучылар Фаина апаларының ике ягына өчәрләп утырдылар.

Фаина ханымның күкрәгендә сигез медаль, өч орден балкый. Аларның һәркайсы – онытылмас вакыйгалар истәлеге. (М.Маликовадан)

**Бирем.** Саннарны табып, төркемчәләрен билгеләргә.

**Җавап.** Егерме – микъдар, беренче – тәртип, өч-дүрт – чама, ике – микъдар, сигез – микъдар, өч – микъдар.

**Диктант**

**Карабодай.**

Карабодай – бик кыйммәтле ярма. Ул химик составы буенча кыяклы ашлыклар бөртегенә якын тора. Моннан тыш карабодайда тагын минераль тозлар да күп була. Аның ярмасы ашказанында яхшы эшкәртелә һәм диетик ашамлык буларак та кулланылырга мөмкин.

Табигать шартлары уңай булганда, бер гектар карабодайдан умарта кортлары 60-90 килограммга кадәр тәмле, файдалы бал җыялар. Бу яктан да аның әһәмияте зур.

Карабодай Татарстанда да игелә. (М.Лапиннан)

**Бирем.** Алмашлыкларны табып, асларына сызарга.

**Җавап.**Ул, аның,бу.

**Контроль диктант**

**Март.**

**Тиздән кыш бетәр, яз башланыр. Инде көндезге кояш кар ныгытмаларын вата.** Бөтен җирдә тамчы тамганы ишетелә.

Иртән өстә кояш балкый, аста кар ялтырый. Өйләр янында чыпчыклар күңелле чыркылдый һәм күгәрченнәр гәрләшә. Урманда тукраннар барабан кагалар. Март аенда урман да җанлана. Агач ботакларында бөреләр бүртә. Каен, талларның ботаклары соргылт төскә керә.

Һәркайда сыерчыклар өчен оялар куела. Карга, чәүкә, саесканнар күлләвектән су эчә. (Н.Сладковтан.)

**Бирем.** Бирелгән җөмләләрдәге фигыльләрнең заманнарын билгеләргә.

**Җавап.**Бетәр- билгесез кил.з. хикәя ф., башланыр-билгесез кил.з. хикәя ф., вата-хәз.з. хикәя ф.

**7 нче сыйныфның татар төркеме өчен татар теле буенча бәяләү материаллары**

**Изложение**

**Батырлык.**

1945 нче елның язы. Сугышлар инде фашистларның үз оясы Германиядә бара. Җиңү көннәре якынайганнан-якыная.

Шулай бер иртәдә безнең танкистларга дошманның зур көчләрен юк итәргә приказ бирелә. Безнең танклар һөҗүмгә күчә. Әнә гвардия лейтенанты Нәҗип Хаҗи- повның алгы сафта барган машинасы фашистларның ике танкын яндырды, өченчесен таранлады. Башка танкистлар уң яктан килеп чыккан зур һәм килбәтсез «Тигр» маркалы танкка бер-бер артлы дүрт снаряд җибәрделәр. Ул дөрләп яна башлады.

Тагын ике «Тигр» күренде. Аларның берсе зур тубын Нәҗип Хаҗипов танкына төзи башлады. Тик Хаҗипов сугышчылары алданрак атып өлгерде һәм «Тигр» сафтан чыкты. Әллә каян яңадан немецларның дүрт танкы килә башлады. Лейтенант Хаҗипов тубын беренчесенә төбәп атты. Тагын корды, тагын атты. Фашист танклары яна башладылар.

Кинәт аның машинасына да яндыргыч снаряд тия. Танк яна башлый, эченә ут ялкыннары, төтен ургылып керә. Лейтенантның киемнәренә ут каба. Тик ул танкыннан чыгып, уттан котылырга уйламый да, көч-хәл белән дошманның соңгы танкына төзәп ата, аны яндыра. Үзе эчкә авып төшә.

Шушы батырлыклары өчен Нәҗип Хаҗиповка Герой исеме бирелә. Аның фамилиясе элек ул хезмәт иткән хәрби частьның исемлегенә мәңгелеккә кертелгән, һәр көнне кичке барлау вакытында аның фамилиясе әйтелә. Шулай аның исеме мәңгеләштерелде. (189 сүз.*)*
*(С.Шакирдан)*

**Диктант**

**Табигатьне өйрәнүче фәннәр.**

Кешеләр борынгы заманнардан ук табигать серләренә төшенергә тырышканнар. Туган ягын, аның табигатен яратучыларның яңадан – яңа сораулары туган. Җавап эзләп, кеше табигатькә якыная барган саен, сораулар арта торган. Табигатьне өйрәнүче төрле фәннәр барлыкка килгән. Үскән саен, син дә табигать белән якыннанрак танышасың. Үсемлекләр турындагы фән – ботаниканы, хайваннар турындагы фән – зоологияне өйрәнәсең. Планетабыз Җирне өйрәнүче география фәне, тереклек дөньясын өйрәнүче биология фәне белән танышасың.

Табигатьтәге барлык бәйләнешләрне өйрәнә торган бер фән бар. Ул – экология.

(73 сүз*)* *( Ф.Җ. Ибраһимова “Табигать бизәкләре”)*

**Бирем.** Фигыльләрнең нигезләрен билгеләргә: ярату, җырларга. Шул фигыльләрдән сыйфат фигыльнең 3 заманын ясарга.

**Җавап.** ярат, җырла; ярат-яратучы, яраткан, яратачак; җырла-җырлаучы, җырлаган, җырлаячак.

**Сочинение “Кышкы урман”**

**Диктант**

**Укытучы.**

Кеше олыгая барган саен, аның укытучысына булган мәхәббәте, хөрмәте дә арта бара. Ул тормыш юлында укытучының нинди зур эш эшләвен тирәнрәк аңлый.Тирә - якка бер күз сал, нинди гүзәл корылмалар, биналар, бакчалар, завод – фабрикалар! Һәрберсендә укытучының хезмәте бар, чөнки шунда эшләүче кешеләрне укытучы тәрбияләгән. Шуңа күрә укытучы – һәркемнең күңел түрендә.

Укучылар никадәр югары үрләсәләр, укытучы да шулхәтле югары **күтәрелә.** Беренче космонавт Юрий Гагаринны да укытучы хәреф танырга **өйрәткән.** Аннары Гагарин белән бергә йолдызлар дөньясына күтәрелгән.

Җирдә һәрбер һөнәр кадерле, кирәкле. (80 сүз) *(“Журналист язмасы”ннан)*

**Бирем.** Фигыльләрдән инфинитив ясарга.

**Җавап.** күтәрелә-күтәрелергә, өйрәткән-өйрәтергә.

## Диктант

### Җылы яңгыр.

Иртән көн матур иде. Кинәт көнбатыштан болыт күтәрелде. Йомшак кына яңгыр җиле исте. Бакчадагы агач яфраклары җәй исен аңкытып җилфердәштеләр. Күктә кошлар чыркылдап очты. Мондый көннәрдә яңгыр болыты бик тиз килә бит. Менә эре тамчылар шып та шып төшә башладылар.

Җылы яңгыр көчәйде. Яңгыр суы урам читендәге канауларга сыймады, тротуар өстеннән акты.

Шаулап килгән яңгыр болыты, ничек тиз килеп җитсә, шулай ук тиз үтеп тә китте. Кояш, элеккедән дә матуррак булып, болыт астыннан чыкты. Күктә аллы-гөлле төсләргә буялган салават күпере калыкты. Җәйге җылы яңгырдан соң гына була торган саф һава күкрәкләрне рәхәтләндерде. (82 сүз.) *(Г. Бакировтан)*

**Бирем.** Аваз ияртемнәрен һәм аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләрне табарга.

**Җавап.** җилфердәштеләр, чыркылдап, шып та шып, шаулап.

## Контроль диктант

### Агыйдел.

Тыныч кына аккан көмеш сулары, яшел тугайлары, кош-корт, киек җанварлар белән тулган урманнары, андагы җиләк-җимешләре, чылтырап аккан чишмә-инешләре Агыйделнең матурлыгына кабатланмас нур өстиләр. Аның ярына басып карап торсаң, күңелне кузгата торган күренеш ачыла. Агыйделгә зәңгәр чишмәләр, бихисап сандагы эреле-ваклы елгалар кушыла. Тирә-юнендә сазлыклар, җикән һәм камыш үсә торган күлләр җәелеп яталар. Урман-әрәмәләр яр кырыйларына сырышып үскәннәр. Агыйдел турында халык кабатланмас шигырьләр иҗат иткән һәм җырлар юллаган.

Кайгы-сагышларны тарата торган, халык күңелен биләп алган су ул Агыйдел. (76 сүз) *(Фирдәвес Гарипова буенча.)*

**Бирем.** Ярдәмче сүз төркемнәренә сызарга.

**Җавап.** кына, белән, һәм.

## 8 нче сыйныфның татар төркеме өчен татар теле буенча бәяләү материаллары

## Изложение

### “Сөйкемсез песи”.

Безгә аклы-сарылы песи баласы кереп иярләште. Үзебезнең бер песиебез бар иде инде. Ул песиебез үзе ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Төсе матур булганы өчен генә түгел, без аны акыллы булганы өчен дә яратабыз. Ул үзе, бик шаян булса да, ашамлыкка тими. Күршеләргә дә кереп йөрми. Песиебезне мактаганда, мине дә мактыйлар. Аны Гөлкәй шулай өйрәткән инде, диләр.

Ә күршедән кергән песи бик тәртипсез булып чыкты. Бертуктаусыз «мияу-мияу» ди. Ашарына бирсәң, төрле җиргә өстерәп алып китә дә идәнне буяп бетерә. Өстәлгә менеп, икмәк сынықларын тартып төшерә. Тагын әллә нинди тәртипсезлекләр эшли...

Беркөнне минем белән уйнарга иптәш кызым Мәйсәрә керде. Ул, безгә ияләшкән песи баласын күргәч, исе китеп:

-Абау, бу юньсез песине нигә керттегез? Ул инде бик күп кешегә йөрде. Бездә дә булды. Аны Рәйсәләр дә, Әнисәләр дә куалап чыгардылар, ул акылсыз, сөйкемсез песи,— диде.

-Ә мин анны куалап чыгармыйм, тәртипкә өйрәтәм,— дидем мин. Абыем Шамил дә:
-Сынап карыйк, өйрәнмәсә үзенә үпкәләр,— диде. Без, Шамил абыем белән икәүләп, песине өйрәтә башладык. Аңар ашарга да, йокларга да урыннар әзерләдек. Бер ай дигәндә, ул бөтенләй үзгәрде: матурланды, түгәрәкләнде, акыллыланды.

**Диктант**

**Кошлар.**

Кошлар көз көне җылы якка очып китәләр, урманнар бушап кала. Яз җитү белән алар тагын кайталар. Гаҗәеп матур тормыш башлана.

Кошлар монда, безнең янда булганда, урман чыр-чу һәм җыр тавышлары белән тула. Кайдадыр бүтән җирдә, диңгез һәм таулар артында, урманнар буш һәм саңгырау булып калалар. Без андый чакта сагынабыз, җәен кошларның җыр һәм матур авазларын күбрәк тыңлап калмаганбыз дип, үз-үзебезне тиргибез.

Су дулкынының яз саен үзеннән үзе артуына ияләнгәнбез без. Әгәр бервакыт ул артмаса? Болыт сирәкләнмәсен өчен без барысын да эшлибезме соң?

Җир өстендә кошлар дулкыны, тере болытлар күчενә. Алар өстендә күк йөзе сафмы соң? Алар астында җир мөлаеммы соң? (99 сүз.)*(Н. Сладков.)*

**Бирем.** 1 абзацтагы җөмләләрнең баш кисәкләрен билгеләргә

**Сочинение “Әдәпле булу-тәрбия билгесе”**

**Диктант**

**Яз җитә бит.**

Табигатьтә яз билгеләре күренә башлады. Ерактагы кара урман**,** ничектер, күгелҗемләнеп, яшәреп китте. Өй түрендәге миләш ботаклары да яшелрәк төскә керделәр. Түбә читләрендә боз сөңгеләре күренде. Чана юллары шомардылар, караеп калдылар. Менә яз хәбәрчеләре- кара каргалар- килеп, су буендагы биек талларга, тирәк башларына оя кордылар.
Кояш җиргә хәзер турырак карый, ышык җирләрдә сизелерлек җылытты. Тереклек чыганагы- кояш-табигатькә әнә шулай җан кертте. Кешеләрдә эшкә дәрт артты, күңелләр күтәрелде. Чәчү машиналары, сабан, тырмалар барланды, амбар ишекләре ачылды. Билгеле, кояш мәктәпкә дә җан иңдерде. Балаларның ыгы-зыгылары башланды. Тиздән- имтиханнар. (87 сүз) ( Г. Гобәй)

***Бирем.*** *Кереш сүзләрне билгеләргә*
***Җавап:*** *ничектер,билгеле.*

**Контроль диктант**

**Май.**

Май-матур аяк басты туган ягыма!

Майсыз кар бетми, дигән сүзне дөресләгәндәй, урмандагы коры елга төбендә дә карның эзе калмады. **Җирне сусыл яшь үлән, агачларны озын һәм кызгылт песиләр, яшел яфраклар каплады. Х**әзер кая карама шунда чәчәк… Табигать нинди иркен сулый! Хәтта сылу каеннар да чынлап торып җылы көннәр җитүенә ышанды, җилемле һәм хуш исле яфрагын ача башлады. Яңгыр һәм якты чыклар белән юынып, озын саргылт алкаларында энҗе-тамчылар асылындырып, күз чагылдырырлык балкуын, яшь ара елмаюын күрүе нинди күңелле!

Тирә-яктагы күркәм үзгәрешләрне җимеш бакчасында үсеп утырган алмагачлар да шәйләде. Барын күреп, барына сокланып, ә бигрәк, чыннан да җылы көннәр килүенә ышанып, зур кызгылт бөреләрен ача башлады. (100 сүз.) *(Гарәфи Хәсәновтан.)*

**Бирем.** Бирелгән җөмләгә тулы синтаксик анализ ясарга

**Җавап:** Җирне сусыл яшь үлән, агачларны озын һәм кызгылт песиләр, яшел яфраклар каплады.
Гади ,хикәя, тулы ,ике составлы, җәенке, раслау , тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган җөмлә.

**9 нчы сыйныфның татар төркеме өчен татар теле буенча бәяләү материаллары**

## Изложение
## Туган җир.

Сандугач бишенче төн оча инде.

Ара ерак, юл авыр. Кайбер кошлар барып та җитмәс. Тик алар моны белмиләр әле. Бар ышанычлары - канатларында. Юлга кузгалганчы, алар үз канатларын ныгыттылар.

Сандугачның үзе дөньяга килгән туган ягына беренче тапкыр әйләнеп кайтышы. Ул анда очарга, үзе яшәгән тирәлекне танырга өйрәнгән, әмма бер тапкыр да сайрап карамаган иде әле. Юлдашлары да нәкъ шулай. Сандугачларның бер төркемендә яшь тә тулмаган бала кошлар гына, һәммәсе дә ана кошлар. Алар юлга үзләренең булачак парларыннан соң кузгалды. Булачак парлары юлга аларга караганда алданрак чыгып китте. Иң соңыннан аларны дөньяга китергән елеккеге әти-әниләре очачак. Гомер-гомердән килгән гадәтләре шундый. Хәер, хәзер инде алар да юлдадыр. Туган җирләрендә аларны кунып сайрар таллары, туй җырлары, куаклар арасында бер-берсе белән кавышасы аулак урыннары, оя кору мәшәкатьләре һәм бала чыгару, аларны үстерү, очарга өйрәтү авырлыклары көтә.

Ләкин төн урталары тирәсендә ул тезелешеп очкан кошлар көтүеннән аерыла язды. Ачык диңгез өстендә каршы яктан килгән давылга очрадылар.

Көчле, дымсу һава агымы сандугачны әледән-әле артка алып ташлады. Тик бу аның күңелен төшермәде, җанына курку иңдермәде. Ярсу җил арттан иссә, күпкә начаррак, хәвефлерәк булыр иде.

Сандугач, соңгы маягыннан тайчынмас өчен, бер һава агымыннан икенчесенә күчә-күчә, төрле якка тал**пынып** оча башлады: әле өскә күтәрелде, әле аска ташланды. Канат кагышлары белән йөрәк тибешләре чу**алды,** бер-берсен **тыңлый алмас** хәлгә килде. **Йолдызлар** юклыгы һәм әйдәүче магнит дулкыннарының бозылуы юнәлешне дөрес тотарга комачаулый иде. Күздән югалган иптәшләрен чакырып, ул әледән-әле тавыш биргәләп барды.

Көтмәгәндә каршы яктан колак тондыргыч гөрелте ишетелде. Сандугач юлдашларына тагын чакыру авазы салды. Әмма бу юлы үз тавышының дулкыннардан кайтарылган кайтавазын тоймады. Аны канатларын хәлсез иткән курку хисе биләп алды. Каршы җил китереп бәргән ачы төтен сулышын кисте. Аңа бу гөрелтенең һәм төтеннең чыганагы яхшы билгеле. Озын һәм очлы томшыклы, хәрәкәтсез каткан канатлы һәм ут койрыклы тимер кошлар шулай саңгыраулашып гөрелдиде, күңел болгаткыч исе белән тынны буа. Гадәттә сандугачлар, бу тимер кош күренүгә, лачыннан өреккән шикелле, төрлесе төрле якка качалар иде.

Каршыдан килгән тимер кошның күзләреннән бәреп торган нур көлтәләре болытларны тишеп чыкты, сандугачны бераз вакытка сукырайтып калдырды. Иләмсез тимер кош туп-туры аңа таба очып килә иде. Сандугач нишләргә дә белми калды, канатлары хәлсезләнде. Әмма ул чигенә, читкә тайпыла алмый иде инде, алда - туган җир. (356 сүз.) *(Ә.Гаффардан)*

## Диктант
## Җәйге кояш астында.

Эссе җәй көне. Кояш әле күкнең уртасына менеп җитмәгән булса да, иртә белән бакчада үләннәргә, агач яфракларына төшкән чык тамчылары инде күптән кибеп беткәннәр. Үләннәр, берсе астына берсе капланып, агач яфраклары кызулыктан әлсерәшеп салынышканнар. Бары түтәл өстен тутырып үскән аклы-кызыллы, зәңгәрле чәчәкләр генә кызудан ул хәтле аптырашмыйлар. Иртә белән бакчачы, бакчага кереп, аларның төпләренә су сибеп чыккан. Шуңа күрә алар, рәхәтләнеп, башларын зәңгәр күккә таба сузалар.

Менә бер түтәлнең нәкъ уртасында яңа гына ачылган ак ләлә чәчәге утыра. Ул башын бүтән чәчәкләрдән югарырак күтәргән. Ул әле кичә кич белән генә ачылган. Дөньяны әле аның беренче тапкыр гына күрүе. Шуңа күрә ул, исе китеп, тирә-ягына карана. Тирә-ягы төрле чәчәкләр, төрле үләннәр белән тулы. **Үлән араларында төрле матур кортлар тәгәрәшә, үрмәкүчләр сикерешеп йөриләр**. Чикерткәләрнең чырылдавыннан колаклар тонарлык. (123 сүз) *(Гарәфи Хәсәнов буенча)*

**Бирем.** Бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясарга.

**Җавап.** Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Гади җөмләләр үзара тезү юлы белән бәйләнгән. Бәйләүче чара – санау интонациясе. Санау интонациясе белән бәйләнгән гади җөмләләр арасына өтер куела.

**Сочинение “Кем булырга?**

**Диктант**

**Сентябрь.**

Алтын көз килеп керде урманга. Яз башыдай, урманнар инде үтә күренә. Сары яфраклар гына кыштырдап коела.

Бик сәер вакыт ул. **Үзе тын, үзендә, яз көнендәге кебек үк, җыр ишетелә**…

Серкә үләннәре ерактан күзгә ташлана. Алар яз уртасында чәчәк аттылар. Нәни һәм ялгыз сабаклы иделәр. Хәзер, ак чәчәкләрен балкытып, кечкенә куак булып алдылар. Сабаклары вак җимешчекләр белән капланып, меңләгән орлыкларын сибәргә - үрчергә әзерләнәләр.

Ала миләүшәләр кар китүгә чәчәк аткан иделәр. Хәзер, көз килеп, кырлар бушауга, ак чәчәкле, шунда ук өлгергән җимешле дә булдылар. Җимешләре бик кызык: өч якка ачылмалы. Капкачлары сай көймәләргә охшаган. Көймәләргә вак орлыклар тулган.

Алар янында кыр кыналары матурланып утыра. Пешергеч нурлардан, өшеткеч яңгырлардан сакланып, чәчәкләре яфрак асларына кача. Җимешләре бигрәк тә иркә: тар яшькелт шешә шикелле, үтә күренмәле. (119 сүз) *(Гарәфи Хәсәновтан.)*

**Бирем.** Бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясарга

**Җавап.** Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Гади җөмләләр үзара тезү юлы белән бәйләнгән. Бәйләүче чара – каршы кую интонациясе. Каршы кую интонациясе белән бәйләнгән гади җөмләләр арасына өтер куела.

**Диктант**

**Көз килде.**

Әле кайчан гына ямь-яшел җәй иде. Кошлар җыры белән гөрли иде урманнар. Безнең тәрәзә каршында да зифа буйлы, бөдрә чәчле каен кызы җилфердәп тора иде. Җәй көннәрендә аңа нинди генә кош кунмады да ничек кенә сайрамады!

Ә хәзер дөнья тынып калды. Көз килде дә каен яфракларын сап-сары буяуга манып китте. Ә җил минем мескен дустымны кочаплап алды да дер селкетте. Сары яфраклары шыбырдап җиргә коелды. **Бу көннәрдә кошлар да ерак-ерак илләргә китеп бардылар, шунлыктан каен кызы яп-ялангач торып калды**. Аңа бик салкын булыр инде.

Әмма борчылмыйм. Менә атна-ун көн узар да, ак тунын кигән кыш бабай килеп җитәр. Ул җирне ап-ак юрган белән каплап китәр. (119 сүз.) *(Нәби Дәүли.)*

**Бирем. Бирелгән җөмләдә тыныш билгесенең куелышын аңлатырга.**

**Җавап.** Бу аналитик иярченле кушма җөмлә. Бәйләүче чара – шунлыктан ялгызак мөнәсәбәтле сүз. Баш җөмлә иярчен җөмләдән соң килгән. Мондый очракларда гади җөмләләр арасына өтер куела

**Контроль диктант**

**Гөлләр.**

Гөлләр арасында иң яратканым – тамчы гөл минем. Бигрәк матур шул аның чәчәге! Бөреләнүгә үк, нәкъ тамчыдай була. Ә берничә көн үтүгә, тамчы сыман бөре ачыла башлый һәм зурайганнан – зурая, аннары бик матур зәңгәр кыңгырауга әйләнә.

Сезнең дә күргәнегез бардыр инде аны. Нинди генә буяулар юк аның төсендә! **Бармак белән кагылсаң, күңелле тавыш чыгарып шалтырар төсле тоела ул зәңгәр кыңгырау.**

Үткән яз уку елын тәмамлап кайттым да беркөн тамчылы гөл утырттым. Җәй буе шактый зур булып үсте ул. Юан-юан берничә ботак чыгарды. Сентябрь килеп җиткәндә, аның өсте чәчәккә күмелгән иде.

Беренче сентябрь көнне бер кулыма – портфелемне, икенчесенә тамчылы гөлемне тоттым да мәктәпкә киттем. Көн шундый матур, шундый җылы!

Классташ кызларым да гөлләр китергән. Тәрәзә төпләрен гәлләр бизәгәч, безнең класс яңа күлмәк кигән кеше төсле чибәрләнеп китте. (126 сүз) *(Мәсгут Кәримовтан.)*

**Бирем.** Бирелгән җөмләгә синтаксик анализ.

**Җавап.** Иярченле кушма җөмлә. 1 нче җөмлә - **бармак белән кагылсаң,** 2 нче җөмлә - **күңелле тавыш чыгарып шалтырар төсле тоела ул зәңгәр кыңгырау.** Гади җөмләләр үзара ияртү юлы белән бәйләнгән. Бәйләүче чара – **-саң** кушымчасы. Мәгънәсе буенча – шарт, төзелеше буенча – синтетик җөмлә. Синтетик шарт җөмләләрдә гади җөмләләр арасына өтер куела.